# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 өлешендә «граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны исәпкә кую кенәгәләрен сатып алуга» сүзләреннән соң «, юридик әһәмиятле гамәлләр кылуга» сүзләрен өстәргә;

2) 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы алтынчы һәм җиденче абзацларында «Федераль теркәү хезмәте» сүзләрен «граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 нче кушымтаның 2 пунктындагы алтынчы һәм җиденче абзацларында «Федераль теркәү хезмәте» сүзләрен «граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 18-ТРЗ